Республика Татарстан

СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Школьная, 31а
тел. 2-30-32, 2-31-35
Факс 8(84362) 2-32-35

e-mail:
sab.sab@tatar.ru

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.б., Мәктәп урамы, 31а йорт
тел. 2-30-32, 2-31-35
Факс 8(84362) 2-32-35

РЕШЕНИЕ КАРАР

«13» май 2019 ел № 16

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең 2017нче елның 7нче ноябрендә 34нче номерлы карар белән расланган “Саба шәһәр җирлегендә төзекләндерү кагыйдәләре”нә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасының 12.02.2019 ел №02-01-20-2019 хаты нигезендә һәм халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләреннән соң, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2017нче елның 7нче ноябрендә кабул ителгән 34нче номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең I бүлеге 6 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

“арбороцидлар” – агач-куак чүп үсемлекләренә каршы кулланыла торган химик матдәләр;

“Сосновский балтырганы” –э ре үлән үсемлек, зонтиклылар гаиләсеннән балтырган төре. Үсемлек озак төзәлә торган көчле пешерү сәләтенә ия;

“гербицидлар” – үсемлекләрне юк итү өчен кулланыла торган химик матдәләр;

1.2. Кагыйдәләрнең III бүлеге 50 пунктын түбәндәге эчтәлекле 50.14 пунктча белән тулыландырырга:

“50.14) үләннәрне даими чабу, чүп үләннәрен һәм куакларын юк итү, бигрәк тә кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручыларын, шул исәптән Сосновский балтырганын.

Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү аларның чәчәккә бөреләнүенә һәм чәчәк ату чорына кадәр башкарылырга тиеш.

Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү түбәндәге ысуллар белән башкарылырга мөмкин:

- Химик- үсеп чыгу учакларына гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү;

- Механик – чабу, корыган үләннәрне җыю, тамыр системасын казып алу;
- Агротехник- туфракны эшкәртү, купьеллык үләннәр чәчү.

1.3. Кагыйдәләрнең IV булеге 113.5 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

"113.5. үләннәрне даими чабу (15 см-дан биегрәк булса), махсус билгеләнгән һәм чикле кулланыштагы яшелләндерелгән территорияләрдән тыш,чүп үләннәрен һәм куакларын юк итү, бигрәк тә кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне, шул исәптән гомумкулланылыштагы җирләрдәге Сосновский балтырганын, һәм чабылган үләнне тәүлек эчендә җыештыру"

1.4. Кагыйдәләрнең IV булеге 114 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 2-5 абзацлар белән тулыландырырга:

"Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү аларның чәчәккә бөреләнүенә һәм чәчәк ату чорына кадәр башкарылырга тиеш.

Сосновский балтырганын һәм башка кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы үсемлекләрне юк итү түбәндәге ысуллар белән башкарылырга мөмкин:

- Химик- үсеп чыгу учакларына гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү;
- Механик – чабу, корыган үләннәрне җыю, тамыр системасын казып алу;
- Агротехник- туфракны эшкәртү, купьеллык үләннәр чәчү."

2. Әлеге карар халыкка хәбәр ителгән көннән үз көченә керә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ saba адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарылырга тиеш.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Р.М.Хәсәнов